**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**СОВЕТ КАРАМЫШЕВСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

Улица Школьная, дом 5, село Карамышево, 423119

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
**КАРМЫШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**СОВЕТЫ**

Мәктәп урамы, 5 йорт, Кармыш авылы, 423119

тел./факс 8439642223 email: Karam.Cmn2@tatar.ru

**№65** **19.05.2022ел**

**Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы**
**Кармыш авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Кармыш авыл җирлеге Советының 2014 елның 17 декабрендәге 82 номерлы «Кармыш авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнарның керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук Кармыш авыл җирлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турында нигезләмәне раслау хакында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында**

2022 елның 1 апрелендә кабул ителгән «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» гы 90-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Кармыш авыл җирлеге Советы КАРАР КЫЛДЫ:

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Кармыш авыл җирлеге Советының 2014 елның 17 декабрендәге 82 номерлы карары белән расланган «Кармыш авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнарның керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук Кармыш авыл җирлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турында нигезләмәнең 7 бүлекнең «в» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«в) хисап чоры өчен (1 гыйнвардан 31 декабрьга кадәр) үз чыгымнары, шулай ук җир кишәрлеге, башка күчемсез милек объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр, (оешмаларның устав (җыелма) капиталларында катнашу өлеше, пайлары), санлы финанс активлары, санлы валюта сатып алу буенча һәр алыш-биреш буенча үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында, әгәр дә мондый алыш-бирешләрнең гомуми суммасы алыш-бирешкә кадәрге соңгы өч ел өчен әлеге затның һәм аның хатынының (иренең) гомуми кеременнән артып китсә, һәм алыш-биреш кылу өчен чараларны алу чыганаклары турында белешмәләр».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Кармыш авыл җирлеге
башлыгы, Совет рәисе И.И.Фәтхетдинов